ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 апрель, 2018 ел № 24/7

Аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 569 санлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы «Бюджет сферасы хезмәткәрләре хезмәтенә түләүнең Бердәм тариф челтәренә кермәгән бюджет сферасындагы аерым оешма хезмәткәрләре хезмәтенә түләү хакында» 195 санлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге «Гражданнар оборонасы, халыкны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү хакында Нигезнамәне раслау хакында» 1097 санлы Карары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәне 1 нче

кушымтада каралганча расларга.

2. Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге «Хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелгән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләү шартларын билгеләү турында» 39/8 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2016 елның 08 июлендәге 9/8, 2016 елның 15 декабрендәге 13/9, 2017 елның 29 мартындагы 16/6, 2017 елның 10 августындагы 18/5, 2018 елның 21 февралендәге 23/8 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге 6 нчы пунктча белән тулыландырырга:

«6) «Янгыннан коткару отряды» муниципаль бюджет учреждениесенең аерым категория хезмәтәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәне 6 нчы кушымтада каралганча»;

2) муниципаль белем бирү оешмаларының һөнәри квалификация группалары вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә, 86 нчы, 87 нче пунктларны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«86. Оешма җитәкчесенә стимуллаштыру түләүләрен Башкарма комитет билгели. Стимуллаштыру түләүләре оешма эшчәнлеге критерийларына нигезләнгән оешма эшчәнлеге нәтиҗәләрәннән чыгып билгеләнә һәм җитәкче, җитәкче урынбасарлары һәм баш хисапчыны стимуллаштыру фондының 50 процентын тәшкил итә. Стимуллаштыру түләүләре ай саен, квартал саен, еллык хезмәт нәтиҗәләре, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен, Башкарма комитетның стимуллаштыру түләүләре бүлеп бирү комиссиясе беркетмәсе нигезендәге карары белән бирелә.

87. Оешма җитәкчесенә стимуллаштыру түләүләре хакында объектив карар кабул итү максатыннан чыгып, җитәкче, җитәкче урынбасарлары һәм баш хисапчыга стимуллаштыру түләүләре акчаларын бүлеп бирү комиссиясе оештырылырга мөмкин. Аның составы һәм вәкаләтләре башкарма комитет карары белән билгеләнә. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аның нигезендә Башкарма комитет тарафыннан җитәкчегә стимуллаштыру түләве бирү турында муниципаль-хокукый акт кабул ителә.»

3) муниципаль учреждениеләрнең физик культура һәм спорт һөнәри квалификация группасы вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә 86 нчы, 87 нче пунктларны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«86. Башкарма комитет оешма җитәкчесенә стимуллаштыру түләүләре билгели ала. Стимуллаштыру түләүләре оешма эшчәнлеге критерийларына нигезләнгән оешма эшчәнлеге нәтиҗәләрәннән чыгып билгеләнә һәм җитәкче, җитәкче урынбасарлары һәм баш хисапчыны стимуллаштыру фондының (ул әлеге Нигезнамәнең 99 нчы пунктында каралган тәртиптә формалаштырыла) 50 процентын тәшкил итә. Стимуллаштыру түләүләре ай саен, квартал саен, еллык хезмәт

нәтиҗәләре, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен, Башкарма комитетның стимуллаштыру түләүләре бүлеп бирү комиссиясе беркетмәсе нигезендәге карары белән бирелә.

87. Оешма җитәкчесенә стимуллаштыру түләүләре хакында объектив карар кабул итү максатыннан чыгып, җитәкче, җитәкче урынбасарлары һәм баш хисапчыга стимуллаштыру түләүләре акчаларын бүлеп бирү комиссиясе оештырылырга мөмкин. Аның составы һәм вәкаләтләре Башкарма комитет карары белән билгеләнә. Комиссия оештырылган очракта, оешма җитәкчесе аның утырышларында катнашырга һәм кирәкле аңлатмалар бирергә хокуклы. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аның нигезендә Башкарма комитет тарафыннан җитәкчегә стимуллаштыру түләве бирү турында муниципаль-хокукый акт кабул итә.».

4) әлеге Карарның 2 нче кушымтасына нигезләнеп, 6 нчы кушымтаны өстәргә.

3. Гамәлдән чыккан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2017 елның 20 июнендәге «Хезмәтләренә түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә башкарылган муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә түләү шартлары турында Нигезнамәне раслау хакында» 17/5 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2017 ел, 05 июньдәге 48 нче санында бастырылган;

2) Шәһәр Советының 2017 елның 19 сентябрендәге «Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне арттыру турында» 19/5 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2017 ел, 27 сентябрьдәге 71 нче санында бастырылган;

3) Шәһәр Советының 2018 елның 21 февралендәге «Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренен хезмәтенә түләү турында Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү хакында 23/8 санлы Карарының 7 нче пунктын, «Челнинские известия» газетасының 2018 ел, 14 марттагы 17 нче санында бастырылган.

4. Әлеге Карар, хезмәтләренә түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә башкарылган муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренә түләү шартлары турында нигезләмәләрдән башка, рәсми бастырылган көннән гамәлгә керә.

Әлеге Карарның хезмәтләренә түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә башкарылган муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренә түләү шартлары турында нигезләмәләре 2018 елның 01 апреленнән соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

5. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев